Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 сентябрь 2021 ел № 77

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 16 июнендәге 473 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Әлмәт муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 08 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ :

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 16 июнендәге 473 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Әлмәт муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 26 июлендәге 303 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Исемлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль мөлкәне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга тапшыру өчен исемлекне булдыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында;

1.2. Преамбулада һәм 1 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1.3 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең исемендә һәм 1.1 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1.4 1 нче кушымтаның «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенең 1.2 пунктында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы”нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мингазов И.М.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов